проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кетрелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында**

1 статья. **Әлеге Законны җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең хокукый нигезләрен билгели.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары структурасына кертелгән, үз компетенциясе чикләрендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы һәм шушы максатларда Татарстан Республикасы карамагындагы предметлар һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы уртак карамагындагы предметлар

буенча вәкаләтләр, шулай ук Россия Федерациясенең тапшырылган аерым вәкаләтләре бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт органы;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы – эшчәнлеге билгеләнгән компетенция чикләрендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең килешеп эшләүче һәм үзара хезмәттәшлек итүче органнары җыелмасы;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары структурасы - Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Рәисе актлары нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары исемлеге;

4) республика башкарма хакимият органнары - министрлыклар, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына караган башка башкарма хакимият органнары;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы компетенциясе - Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының дәүләт идарәсенең билгеле бер функцияләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләре җыелмасы;

6) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләре – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының хокукый актлар кабул итүгә, шулай ук аның эшчәнлеге өлкәсендә башка дәүләт-хакимият гамәлләрен гамәлгә ашыруга карата хокуклары һәм бурычлары.

2. Әлеге Законда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» һәм «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» төшенчәләре бер мәгънәдә кулланыла.

3 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең хокукый нигезләре**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары үз эшчәнлекләрен Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыралар.

4 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары системасын Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, министрлыклар, Татарстан Республикасы Дәүләт комитетлары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары тәшкил итә.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнә.

5 статья. **Татарстан Республикасы Рәисе**

1. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты булып тора һәм Татарстан Республикасында башкарма хакимияткә җитәкчелек итә.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә сайлана һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында тантаналы шартларда ант биргәннән соң вәкаләтләрен үтәүгә керешә.

3. Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләре Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Рәисе федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Россия Федерациясенең тапшырылган аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы структурасын раслый.

5. Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары имзаланганнан соң 14 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә.

6 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең даими эшләүче югары органы булып тора.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисе алдында җавап бирә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль конституцион законнарның, федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, әлеге Законның, Татарстан Республикасының башка законнарының һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының Татарстан Республикасы территориясендә үтәлешен һәм республика башкарма хакимият органнарының килешенгән эшчәнлеген тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын формалаштыру һәм эшчәнлек тәртибе, аның вәкаләтләре Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка законнары, федераль башкарма хакимият органнары белән килешүләр, шулай ук Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең федераль башкарма хакимият органнарының аерым вәкаләтләрен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына тапшыруны күздә тоткан норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте», «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты», «Татарстан Республикасы Хөкүмәте» атамаларының мәгънәсе бертөрле.

7 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының республика башкарма хакимият органнарына карата вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты республика башкарма хакимият органнарының эшен берләштерә һәм юнәлеш бирә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз компетенциясе чикләрендә:

1) республика башкарма хакимият органнары турында нигезләмәләрне раслый, аларның хезмәткәрләренең чик санын билгели;

2) әлеге Законның 5 статьясының 4 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, республика башкарма хакимият органы структурасын раслый;

3) республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләренең урынбасарларын билгели һәм вазифаларыннан азат итә;

4) республика башкарма хакимият органнары коллегияләре составларын раслый;

5) республика башкарма хакимият органнары актларын гамәлдән чыгарырга яки мондый актларның гамәлдә булуын туктатырга хокуклы;

6) Татарстан Республикасы Конституциясендә, федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, федераль башкарма хакимият органнары белән килешүләрдә, шулай ук Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең федераль башкарма хакимият органнарының аерым вәкаләтләрен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына тапшыруны күздә тоткан норматив хокукый актларында билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

8 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составы һәм структурасы**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Премьер-министрыннан, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларыннан, Татарстан Республикасы министрларыннан, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары рәисләреннән тора.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләрен кертә ала.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының вазыйфалары буенча составы  Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

4. Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән килешү буенча Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы Премьер-министры кандидатурасы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яңа сайланган Татарстан Республикасы Рәисе алдында вәкаләтләрен тапшырганнан соң яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә Татарстан Республикасы Премьер-министры отставкасыннан соң 30 көннән дә соңга калмыйча кертелә.

9 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының вәкаләтләре срогы**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисенең вәкаләтләре срогы чикләрендә эш итә һәм яңа сайланган Татарстан Республикасы Рәисе алдында үз вәкаләтләрен тапшыра. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан үз вәкаләтләрен тапшыру турындагы карар Татарстан Республикасы Рәисе вазифасына керешкән көнне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән рәсмиләштерелә.

2. Вәкаләтләрен тапшырган очракта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының яңа составы төзелгәнче эшләвен дәвам итә.

10 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының отставкасы**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты отставкага китә ала, ул Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кабул ителә яки кире кагыла.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының отставкасы турында карар кабул итә ала.

3. Татарстан Республикасы Рәисенең федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә вазифасыннан китүе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының отставкага китүенә китерә.

4. Отставка очрагында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының яңа составы төзелгәнче эшләвен дәвам итә.

11 статья. **Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфаларын башкару**

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры вакытлыча булмаган очракта, аның вазыйфаларын аның Татарстан Республикасы Премьер-министры яки Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнгән урынбасарларының берсе башкара.

2. Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфасыннан азат ителгән очракта Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Премьер-министры билгеләнгәнче Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфаларын

башкаруны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларының берсенә йөкләргә хокуклы.

**12 статья. Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка әгъзалары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты рәисе булып тора һәм аның эшен оештыра.

2. Татарстан Республикасы Премьер-министры билгеләнүдән соң җиде көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы буенча тәкъдимнәр кертә.

3. Татарстан Республикасы Премьер-министры:

1) Татарстан Республикасында һәм аннан читтә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын тәкъдим итә;

2) Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка әгъзаларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына кермәгән башкарма хакимиятнең республика органнары җитәкчеләрен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү турында тәкъдимнәр кертә.

3) Татарстан Республикасы Рәисенә республика башкарма хакимият органнарын оештыру, үзгәртү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында тәкъдимнәр кертә;

4) хәл итүче тавыш хокукына ия булып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм аның Президиумы утырышларын алып бара;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын имзалый;

6) Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары арасында бурычларны бүлә;

7) үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзаларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына кермәгән республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә һәм Татарстан Республикасы Премьер-министрына буйсынучы башка вазыйфаи затларга бүләкләр һәм дисциплинар җәзалар бирү турында карарлар кабул итә;

8) закон нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

4. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында хәл итүче тавыш хокукы белән катнашалар;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашалар;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелгән тәкъдимнәрне, карарлар һәм боерыклар проектларын алдан карыйлар;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын әзерләүдә катнашалар, аларның үтәлешен тәэмин итәләр;

5) бурычларны бүлүгә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларының һәм боерыкларының үтәлешен контрольдә тоталар;

6) бурычларны бүлүгә ярашлы рәвештә башка вәкаләтләр башкаралар.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка әгъзалары:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында хәл итүче тавыш хокукы белән катнашалар;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын әзерләүдә катнашалар, аларның үтәлешен тәэмин итәләр;

3) әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

13 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы**

1. Оператив мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Премьер-министры тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумын төзи, аның составына вазифалары буенча Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары, шулай ук башка затлар керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы утырышлары кирәк булганда үткәрелә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы карарлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларына каршы килергә тиеш түгел.

4. Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумының теләсә нинди карарын гамәлдән чыгарырга хокуклы.

14 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышлары**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында шәхсән катнашалар.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Югары Суды, Татарстан Республикасы Арбитраж суды, Татарстан Республикасы прокуратурасы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» Ассоциациясе вәкилләре, башка затлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында законнар нигезендә яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә катнашырга хокуклы.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында Татарстан Республикасы Премьер-министры яки Татарстан Республикасы Рәисе рәислек итә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аерым мәсьәләләрне ябык утырышларда карый ала, шулай ук карарларны утырышлар уздырмыйча кабул итә ала.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларын әзерләү һәм үткәрү, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан

утырышлар уздырмыйча карарлар әзерләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

15 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында карала торган мәсьәләләр**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында гына түбәндәге мәсьәләләр карала:

1) Татарстан Республикасы бюджеты проекты турында;

2) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе проекты турында;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы составы турында;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты турында;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында.

2. Башка мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән очракларда, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе яки Татарстан Республикасы Премьер-министры карары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентында билгеләнгән тәртиптә каралырга мөмкин.

16 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе Указлары нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән карарлар һәм боерыклар чыгара, аларның үтәлешен контрольдә тота.

2. Норматив характердагы актлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары формасында чыгарыла. Норматив характерда булмаган, оператив һәм башка агымдагы мәсьәләләр буенча актлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары формасында чыгарыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәлергә тиеш.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар булган карарлардан яки аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан

Республикасы законнары нигезендә таратылырга тиеш булмаган башка мәгълүматлар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары алар басылып чыкканнан соң 14 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокукый характерда булмаган мөрәҗәгатьләрне, гаризаларны һәм башка актларны кабул итәргә хокуклы.

17 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеген тәэмин итү һәм башкарма хакимиятнең республика органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты оештырыла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Татарстан Республикасының дәүләт органы булып тора.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратын Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе җитәкли.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты турында Нигезләмә, аның чик саны, структурасы һәм штат расписаниесе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты юридик зат булып тора, аның мөстәкыйль балансы, казначылык органнарында шәхси счетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы һәм үз исеме белән мөһере, башка мөһерләр һәм штамплары, бланклары бар.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аппараты эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү бу максатларга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

18 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында органнар һәм оешмалар оештыру**

Дәүләт идарәсенең аерым мәсьәләләре буенча мәсьәләләрне килештереп хәл итү өчен, шулай ук үз эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында оешмалар булдырырга, координацион, киңәшмә һәм башка органнар төзергә хокуклы.

19 статья. **Республика башкарма хакимият органнары**

1. Республика башкарма хакимият органнарын оештыру, аларның исемнәрен үзгәртү, үзгәртеп кору, бетерү Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Республика башкарма хакимият органнарын үзгәртеп кору, бетерү белән бәйле мәсьәләләр, шул исәптән үзгәртеп корыла, юкка чыгарыла торган республика башкарма хакимият органнарының функцияләрен һәм вәкаләтләрен тапшыру, хокук дәвамчылыгы мәсьәләләре, Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары яки Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән регламентлана.

3. Республика башкарма хакимияте органының функцияләре, вәкаләтләре, шулай ук аның эшчәнлеге тәртибе башкарма хакимиятнең тиешле республика органы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нигезләмә белән билгеләнә.

4. Республика башкарма хакимият органнарының функцияләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы нигезендә билгеләнә.

5. Республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләрен Татарстан Республикасы Рәисе билгели һәм вазифаларыннан азат итә.

6. Республика башкарма хакимияте органы юридик зат хокукларына ия, казначылык органнарында шәхси счетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы һәм үз исеме белән мөһере, башка мөһерләре һәм штамплары, бланклары бар.

7. Юридик зат хокуклары республика башкарма хакимият органы структурасына мөстәкыйль бүлекчәләр сыйфатында кергән Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, ә аерым очракларда республика башкарма хакимият органының территориаль органнарына бирелә ала.

8. Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү бу максатларга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

9. Республика башкарма хакимият органнары аларның эшчәнлеге өчен кирәкле мөлкәт – биналар, элемтә чаралары, техник җиһазлар, транспорт һәм башка матди-техник чаралар белән тәэмин ителә.

10. Мөлкәтне республика башкарма хакимияте органына беркетү турында карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт белән идарә итүне гамәлгә ашырырга вәкаләтле органы кабул итә.

11. Республика башкарма хакимият органнарына беркетелгән мөлкәт Татарстан Республикасы мөлкәте булып тора һәм аларның оператив идарәсендә тора.

12. Республика башкарма хакимият органын бетерү аны гражданлык законнары нигезендә билгеләнгән юридик зат буларак бетерүгә китерә.

20 статья. **Республика башкарма хакимият органнары актлары**

1. Республика башкарма хакимият органнары үз компетенцияләре чикләрендә үзләре алып бара торган мәсьәләләр буенча норматив хокукый актлар, шулай ук тиешле республика башкарма хакимият органына буйсынучы барлык оешмалар тарафыннан үтәлергә тиешле боерык актлары чыгаралар. Республика башкарма хакимияте органы тарафыннан чыгарылган актларның төрләре әлеге орган турында нигезләмә белән билгеләнә.

2. Федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда, республика башкарма хакимият органнары үз компетенциясе чикләрендә башкарма хакимиятнең башка органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлергә тиешле норматив хокукый актлар, шулай ук гомуми мәҗбүри характердагы норматив хокукый актлар бастырып чыгарырга хокуклы.

3. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

4. Республика башкарма хакимияте органнарының дәүләт теркәвеннән үткән норматив хокукый актлары, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне үз эченә алган актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә таратылырга тиеш булмаган башка мәгълүматлардан тыш, Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә мәҗбүри бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары аларны дәүләт теркәвенә алган көннән 14 көн эчендә республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә.

21 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән хезмәттәшлеге**

1. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча еллык хисаплар, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм нәтиҗәлелеген бәяләү турында җыелма еллык доклад тәкъдим итә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисе кушуы буенча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы соравы буенча яисә үз инициативасы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы законнары проектларын, карарларын эшләүне оештыра һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, башкарма хакимиятнең республика органнары үз инициативалары буенча яки Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы һәм комитетлары соравы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына үзләре караган законнарга һәм закон проектларына рәсми нәтиҗәләр җибәрә ала. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми бәяләмәләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка әгъзалары яки алар тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затлар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында һәм ул төзегән органнар утырышларында киңәшмә тавыш хокукы белән катнашырга хокуклы.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты керткән закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм ул төзегән органнарга тәкъдим итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми вәкиле (рәсми вәкилләре) билгеләнә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгеләгән срокта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алдында үз эше турында хисап бирә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә («Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) һәм «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү зарурлыгына бәйле рәвештә эшләнде.

Кертелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары системасын Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, министрлыклар, Татарстан Республикасы Дәүләт комитетлары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары тәшкил итә. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнә.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы мәсьәләләрен җайга салу Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләренә кертелгән һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән нигезләмәләрнең шактый өлеше законнар дәрәҗәсендә көйләнә алмый. Бу закон проекты белән бәйле рәвештә әлеге Законны яңа редакциядә бәян итү күздә тотыла.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең хокукый нигезләрен билгеләү күздә тотыла. Аерым алганда, аппарат төшенчәсе кертелә, Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының республика башкарма хакимият органнарына карата вәкаләтләре, республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру нигезләре билгеләнә.

Моннан тыш, закон проекты Татарстан Республикасы Конституциясенең 99 статьясының аның нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты компетенциясе, аның эшчәнлеге тәртибе, аның Татарстан Республикасының башка дәүләт хакимияте органнары белән мөнәсәбәтләре Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә торган икенче өлешен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

Моңа бәйле рәвештә, закон проекты белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составын һәм структурасын, Татарстан Республикасы Премьер-министрының, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка әгъзаларының вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәм аның президиумының эш тәртибен һәм башка мәсьәләләрне регламентлау күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.